ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасында гражданнар сәламәтлеге торышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты доклады хакында

Татарстан Республикасында гражданнар сәламәтлеге торышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты докладын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында гражданнар сәламәтлеге торышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты докладын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына гражданнар сәламәтлеген саклау өлкәсендә законнарның гамәлгә ашырылуын тикшереп торуны һәм аларның хокукый кулланылышын мониторинглауны дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Татарстан Республикасы территориясендә «Озак һәм актив яшәү» һәм «Гаилә» илкүләм проектлары чараларын планлаштырылган максатчан күрсәткечләргә ирешеп гамәлгә ашыруны дәвам итүне.

3.2. Көтелә торган, шул исәптән сәламәт, гомер озынлыгын арттыруга, сәламәт яшәү рәвешен булдыруга, күрсәтелә торган медицина ярдәме сыйфатыннан халыкның канәгать булуын арттыруга юнәлдерелгән өстәмә чаралар күрүне тәэмин итүне.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. Ана булуны һәм ата булуны саклау, балаларның һәм яшүсмерләрнең сәламәтлегенә, шул исәптән репродуктив сәламәтлегенә, сакчыл карау өлешендә «Гаилә» илкүләм проекты чараларын гамәлгә ашыруны дәвам итүне.

4.2. Расланган план нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыклары белән берлектә аерым төркемдәге олы кешеләргә диспансеризация, халыкның репродуктив сәламәтлеген бәяләү буенча

профилактика медицина тикшерүләрен һәм диспансеризация оештыру һәм үткәрүне тәэмин итүне.

4.3. Махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм махсус хәрби операция ветераннарына медицина, психология, психология-психотерапия ярдәмен заманча медицина реабилитация технологияләрен кулланып күрсәтү буенча дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләре эшчәнлеген координацияләүне дәвам итүне.

4.4. Сирәк (орфан) авырулардан интегүче затларны, шулай ук гражданнарның ташламага ия категорияләрен дару препаратлары белән тәэмин итү чараларын күрүне.

4.5. Күрсәтелә торган медицина ярдәменең сыйфатын арттыру өчен алдынгы фәнни эшләнмәләрне көндәлек клиник эшкә кертүне дәвам итүне.

4.6. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыклары белән берлектә Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларында кадрлар кытлыгын бетерү буенча эшне активлаштыруны.

5. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручы гражданнарның амбулатор гемодиализ үтү урынына баруын һәм яшәү урынына кире кайтуын оештыруда ярдәм күрсәтү эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 24 декабре
№ 478-VII ДС